МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

18.10.2017 № 577

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифагаурнашу (кадрлар резервына керү) буенча конкурсны үткәрү кагыйдәнамәсенә үзгәрешләрне кертү турында**

“Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифага урнашу конкурсы турында” 2005 ел 1 февраль № 112 Русия Федерациясе Президенты Указына һәм 2017 ел 1 март № 96 Русия Федерациясе Президенты Указы белән расланган Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турыда кагыйдәнамәсенә туры китереп,б о е р а м:

1. 2015 ел 8 июнь № 244 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифагаурнашу (кадрлар резервына керү) буенча конкурсны үткәрү кагыйдәнамәсенә алдагы үзгәрешләрне кертергә:

пункт 3.5 тә “б” пункт астын алдагы редакциядә язырга:

“б) Русия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкетаны, фотография белән;

пункт 3.8 не алдагы редакциядә язырга:

“3.8. Документларкабул ителү турында белдерүне “Интернет” информацион-телекоммуникацион челтәрендә (алга таба – “Интернет”) дәүләт хезмәте өлкәсендәдәүләт информацион системасының рәсми сайтына кертү көненнән бирле 21 календарь көне эчендә гражданин (гражданлык хезмәткәре) документларны Татарстан Республикасы ГТХМ ның кадрлар хезмәтенәтапшыра: үзе, почта буенча яисә билгеләнгән информацион системаны кулланып электрон төрдә. Электрон төрдә документларны тапшыру тәртибен Русия Федерациясе Хөкүмәте билгеләп куя;

пункт 3.9 гаалдагы эчтәлектә икенче абзацны өстәргә:

“Документларны нигезле сәбәп буенча вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен үтәмичә тапшырганда министр аларны кабул итү срокларын күчерергә хаклы”;

пункт 4.4.1 нең икенче абзацына алдагы эчтәлектә җөмләне өстәргә:

“Электрон төрдә тапшырылган мәгълүматлар Русия Федерациясе Хөкүмәте билгеләп куйган тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә куелалар”;

пункт 4.4.1 гә алдагы эчтәлектә бишенче абзацны өстәргә:

“Конкурсның икенче этабы конкурста катнашыр өчен документларны кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көненнән соңга калмыйча үткәрелә, ә дәүләти һәм закон белән саклана торган башка сере булган мәгълүматка рөхсәтне рәсмиләштерү очрагында конкурсның икенче этабын үткәрү срогын министр билгели”;

пункт 4.4.2 не алдагы редакциядә язырга:

“4.4.2. Тикшерү вакытында, Русия Федерациясе федераль законнарына һәм башка норматив хокук актларына туры китереп, гражданинга гражданлык хезмәтенә керергә киртә булган шартлар табылса, министр аныконкурста катнашуда кире кагу сәбәпләре турында язу формасында белдерә. Гражданин конкурста катнашыр өчен документларны электрон төрдә тапшырган очракта конкурста катнашуда кире кагу сәбәпләре турында белдерү дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системасын куллануы белән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында гражданинга җибәрелә”;

4.4.5 пунктның икенче абзацын алдагы редакциядә язырга:

“4.4.5 Конкурсның икенче этабы башланыр алдыннан 15 календарь көненә соңга калмыйча кадрлар хезмәте Татарстан Республикасы ГТХМ ның рәсми сайтына һәм “Интернет” челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәдәүләт информацион системасының рәсми сайтына конкурсны үткәрү датасы, урыны һәм аны үткәрү вакыты турында мәгълүматны, конкурста катнашырга рөхсәт бирелгән гражданнарның (гражданлык хезмәткәрләренең) (алга таба – кандидатлар) исемлеген кертә һәм кандидатларга язу формасында туры килгән хәбәрләр җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашыр өчен документларны электрон төрдә тапшырган кандидатларга – билгеләнгән информацион системасын куллануы белән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында”;

пункт 4.4.6 ны алдагы редакциядә язырга:

“4.4.6. Конкурсның икенче этабын үткәрү датасын, урынын һәм вакытын карар итүе министр белән гражданлык хезмәтенең вакант вазифасына урнаша торган дәгъвалаучы тапшырган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелгәннән соң кабул ителә, шулай да дәүләти яисә закон белән саклана торган башка сере булган мәгълүматларга рөхсәт бирү кирәк булган очракта рәсмиләштергәннән соң.

пункт 4.12 не алдагы редакциядә язырга:

“4.12. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр конкурс тәмамланган көненнән бирле 7 көнлек срокта язу формасында кандидатларга җибәрелә, шул ук вакытта конкурста катнашыр өчен документларны электрон төрдә тапшырган кандидатларга – билгеләнгән информацион системасын куллануы белән

көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук срокта Татарстан Республикасы ГТХМ ның һәм “Интернет” челтәрендә билгеләнгән информацион системасының рәсми сайтларына кертелә.

пункт 4.13 не алдагы редакциядә язырга:

“4.13. Конкурста катнашырга рөхсәт бирелмәгән гражданлык хезмәтенең вакант вазифага урнашмакчыдәгъвалаучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланган көненнән бирле өч ел эчендә язу гариза буенча аларга кире бирелә ала. Бу срок үткәнче, документлар Татарстан Республикасы ГТХМ ның архивында саклананалар, аннан соң аларюк ителергә тиеш. Конкурста катнашыр өчен электрон төрдә тапшырылган документлар өч ел буе саклана, аннан соң алар бетерелергә тиеш”.

2. Боерыкны министр урынбасарларына,Татарстан Республикасы ГТХМ аппаратының структура бүлекләренең җитәкчеләренә һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Биредәге боерыкны үтәү контролен министр урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин